ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы $1^2$ өлешенә, Россия Федерациясе Җир кодексының $10^1$ статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 4 пунктына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре расланган Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләре (алга таба – шәһәр, авыл җирлекләре) җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән, шәһәр, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен шәһәр, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт органнары арасында биш елга яңадан бүлә.

**2 статья**

Әлеге Законның 1 статьясында күрсәтелгән вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан ,Кремль
2015 елның 26 декабре
№ 108-ТРЗ